Республика Татарстан

Глава Менделеевского муниципального района

Татарстан Республикасы

Менделеевск муниципаль районы башлыгы

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

06.02.2020 Менделеевск ш. №22

Халыкның тормыш дәрәҗәсен күтәрү һәм
Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
керемнәрен легальләштерү буенча
район ведомствоара комиссиясе составын раслау турында

Халыкның тормыш дәрәҗәсен күтәрү һәм Менделеевск муниципаль районында рәсми булмаган хезмәт базарын киметү эшчәнлеген тәэмин итү максатларында

КАРАР БИРӘ:

1. Халыкның тормыш дәрәҗәсен күтәрү һәм Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы керемнәрен легальләштерү буенча район ведомствоара комиссиясе составын кушымта нигезендә расларга.

2. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы башлыгының 2019 елның 24 октябрендәге 66 номерлы карары «Халыкның тормыш дәрәҗәсен күтәрү һәм Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы керемнәрен легальләштерү буенча район ведомствоара комиссиясе составын раслау турында» үз көчен югалткан дип санарга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында www.mendelevsk.tatarstan.ru «Документлар» бүлегендә бастырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе Абдуллин Рөстәм Альберт улына йөкләргә.

Район Башлыгы В.С.Чершинцев

КИЛЕШТЕРЕЛДЕ
Менделеевск муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Р.А. Абдуллин

Юридик бүлек башлыгы Е.С.Царева

Кушымта
Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль
районы Башлыгының
2020 елның 6 февралендәге
22 номерлы карарына

Халыкның тормыш дәрәҗәсен күтәрү һәм Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы керемнәрен легальләштерү буенча район ведомствоара комиссиясе
СОСТАВЫ

Комиссия рәисе, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе

Комиссия рәисе урынбасары, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад, сәнәгать һәм эшкуарлык бүлеге башлыгы;

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы башкарма комитетының комиссия секретаре, икътисад, сәнәгать һәм эшкуарлык бүлеге баш белгече;

Комиссия әгъзалары:

Алабуга шәһәрендә дәүләт статистикасының әйдәп баручы белгеч-эксперты (Менделеевск шәһәрендә) (килешү буенча);

"РФ Федераль салым хезмәтенең ТР буенча төбәк бүлекчәсе" ДУнең 13 нче филиалы баш белгече (килешү буенча);

«Менделеевск районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» ДКУ директоры, Менделеевск муниципаль районында Татарстан Республикасы һөнәр берлекләрен оештыруның координация советы рәисе (килешү буенча);

Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча 9 нчы районара инспекциясе башлыгы урынбасары (килешү буенча);

Россия Эчке эшләр министрлыгының Менделеевск районы буенча бүлеге башлыгы урынбасары (килешү буенча);

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары;

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Менделеевск муниципаль районындагы социаль яклау бүлеге башлыгы (килешү буенча);

Бүлек башлыгы - Россия Суд приставлары федераль хезмәтенең ТР буенча идарәсенең Менделеевск һәм Тукай районнары буенча суд бүлеге өлкән суд приставы (килешү буенча);

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районында Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы (килешү буенча);

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы башлыгының коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча ярдәмчесе (килешү буенча);

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының финанс-бюджет палатасы рәисе (килешү буенча);

Чаллы шәһәрендә Россия Федерациясе Пенсия Фонды идарәсенең Менделеевск районында клиент хезмәте җитәкчесе (бүлекнең хокуклары буенча) (килешү буенча);

Россия Федерациясе Тикшерү комитетының Татарстан Республикасы буенча тикшерү идарәсенең Менделеевск районара тикшерү бүлеге җитәкчесе (килешү буенча).